РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

---

**КАРАР** **КАРАР**

15 ноябрь, 2024 ел Кукмара ш. № 275

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендә:

13 пунктта «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә.;

27 пунктта «муниципаль район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны төзү, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

33 пунктта «, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләре» сүзләрен өстәргә;

2) 10 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Районның җирле үзидарә органнары тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы вәкаләтләрен тиешле вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында җирле бюджетларга бирелгән субвенцияләр чикләрендә гамәлгә ашыру өчен җаваплы.»;

3) 30 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9.1 һәм 9.2 пунктлаын өстәргә:

«9.1) хәрби хезмәткә чакырылу яисә аны алмаштыручы альтернатив граждан хезмәтенә җибәрү;

9.2) аның тарафыннан чит ил агенты статусын алу.»;

4) 47 статьяның 1 өлешендә:

8 пунктның 6 абзацында «, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләре» сүзләрен өстәргә

3 пунктның 4 абзацында «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыра һәм үткәрә» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның 7 абзацында «район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыра, үстерә һәм саклауны тәэмин итә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 78 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 нче өлешне өстәргә:

«3. Районның җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.»;

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Район башлыгы С.Д. Димитриев